ГОСУДАРСТВЕННЫЙ
КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА
ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ**

_____19.07.2024___________ №____106-од_________

Казан ш.

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты тарафыннан гамәлгә куючы функцияләре һәм вәкаләтләре башкарыла торган «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесенә архив фондларын һәм җиһазларын ташуга бәйле чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында» 2022 елның 21 декабрендәге 177-од номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

1. Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты тарафыннан гамәлгә куючы функцияләре һәм вәкаләтләре башкарыла торган «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесенә архив фондларын һәм җиһазларын ташуга бәйле чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында» 2022 елның 21 декабрендәге 177-од номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 18 маендагы 1004-р номерлы боерыгы» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты тарафыннан гамәлгә куючы функцияләре һәм вәкаләтләре башкарыла торган «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесенә архив фондларын һәм җиһазларын ташуга бәйле чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктның бишенче, алтынчы абзацларын төшереп калдырырга;

2.5 пунктның җиденче абзацында «чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап» сүзләрен «чыгымнар турында хисап» сүзләренә алмаштырырга;

3.1 пунктта:

икенче абзацта «чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап» сүзләрен «чыгымнар турында хисап» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Гамәлгә куючы өстәмә хисап бирү формаларын һәм срокларын билгеләргә хокуклы. Хисапларның формалары Килешүдә билгеләнә.»;

4.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Гамәлгә куючы Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткечләреннән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараның тәгалләнү фактын күрсәтә торган вакыйгалардан чыгып, субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә (контроль нокта) ирешүгә мониторинг ясый.»;

4.3 пунктның икенче абзацында «1.2 пунктында» сүзләрен «1.3 пунктында» сүзләренә алмаштырырга.

3. Әлеге боерык Тәртибенең 4.1 пунктындагы икенче абзацын 2025 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә, дип билгеләргә.

Рәис Г.З. Габдрахманова